# «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмә

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – АТИ идарәсе) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) карамагындагы юридик зат хокукларына ия, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль норматив хокукый актлар үтәлешен муниципаль контрольдә тоту, төзекләндерү дәрәҗәсен арттыру, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мөстәкыйль орган.

2. АТИ идарәсе оештыручысы (Милекчесе) булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге тора.

АТИ идарәсе оештыручысы хокукларын Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы (алга таба – Оештыручы) гамәлгә ашыра.

АТИ идарәсе мөлкәте милекчесе хокукларын Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Милекче) гамәлгә ашыра.

3. АТИ идарәсе үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе Җир кодексына, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт күзәтчелеген (надзор) һәм муниципаль күзәтчелекне гамәлгә ашыру барышында юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау» 294-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы Җир кодексына, Татарстан Республикасының 2010 елның 30 июлендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә хокуклы вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 60-ЗРТ номерлы законына, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка хокукый актларына, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына, әлеге Нигезләмәгә һәм Яр Чаллы шәһәренең башка муниципаль хокукый актларына (алга таба – муниципаль хокукый актлар) таяна.

4. АТИ идарәсенең тулы рәсми атамасы:

рус телендә: муниципальное казенное учреждение «Управление административно-технической инспекции при Исполнительном комитете муниципального образования город Набережные Челны»;

татар телендә: «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе.

АТИ идарәсенең кыскартылган рәсми атамасы:

рус телендә: МКУ УАТИ;

татар телендә: АТИИ МКУ.

5. Дәүләт теркәве үткән вакыттан АТИ идарәсе юридик зат булып тора, мөстәкыйль балансréférences, штампларга, мөһергә, үз атамасы белән бланкларга ия.

6. АТИ идарәсе Россия Федерациясе законнары нигезендә үзенә кергән средстволар белән шәхси счетлар аша операцияләр башкара.

7. АТИ идарәсе үз исеменнән милек һәм шәхси милек булмаган хокуклар алырга, йөкләмәләр үтәргә, Россия Федерациясе законнары нигезендә судта дәгъвачы, җавап тотучы, өченче зат сыйфатында чыгыш ясарга мөмкин.

8. АТИ идарәсе үз карамагындагы акча средстволары йөкләмәләре буенча җавап бирә. Күрсәтелгән акча средстволары җитмәгән очракта, АТИ идарәсе йөкләмәләре буенча субсидиар җаваплылыкка аның мөлкәт Милекчесе ия.

9. АТИ идарәсенең адресы: 423805, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Х. Туфан проспекты, 23 йорт.

## 2 бүлек. АТИ идарәсе эшчәнлеге предметы һәм максатлары

10. АТИ идарәсе эшчәнлеге предметы һәм максатлары булып җирле үзидарә мәсьәләләрен хәл итү өлкәсендә үз компетенциясе кысаларында идарә функцияләрен башкару, законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшырылган, Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары муниципаль хокукый актлары белән билгеләгән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар үтәлешен контрольдә тоту, Яр Чаллы шәһәре территориясендә санитар торышны, җәяүлеләр һәм транспорт хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шулай ук җир законнарын бозуны кисәтү, ачыклау, булдырмый калу һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләрдән рациональ һәм нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту тора.

## 3 бүлек. АТИ идарәсе компетенциясе һәм вәкаләтләре

11. Әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, башка муниципаль хокукый актлар нигезендә АТИ идарәсе түбәндәгеләргә хокуклы:

1) шәһәрне төзекләндерү, җир законнары өлкәсендә тәртип бозуларны ачыклау һәм булдырмый калу мәсьәләләрен хәл итүдә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары, башка оешмалар, шулай ук юридик, вазыйфаи затлар һәм физик затлар белән билгеләнгән тәртиптә үзара бәйләнешне гамәлгә ашыру;

2) дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, башка оешмалардан вәкаләтләрне башкару өчен кирәкле мәгълүмат, документлар һәм материаллар алу;

3) тикшерүләр акты төзү, административ хокук бозу турында беркетмә төзү.

12. Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты карамагындагы орган буларак АТИ идарәсе вәкаләтләре:

1) үз вәкаләтләре чикләрендә Яр Чаллы территориясендә урнашкан яки үз эшчәнлекләрен алып барган физик һәм юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең төзекләндерү, төзекләндерү объектларында инженерлык-коммуникация (җир), ремонт һәм башка эшләр башкару, яшел утыртмаларны үстерү, карап тоту һәм саклау өлкәсендә норматив хокукый актларны үтәү өлешендәге эшчәнлегенә контрольне гамәлгә ашыру;

2) үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәгеләрне контрольдә тоту:

- юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар тарафыннан җир кишәрлекләреннән файдалану тәртибен һәм аларга хокукның тәмамлануын;

- рөхсәт ителгән файдалану төре буенча җирләрдән файдалануны;

- муниципаль милектәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына һәм аларда урнашкан күчемсез милек объектларына төзелгән килешүләрнең һәм хокукларның дәүләти теркәлүен;

- юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм физик затлар тарафыннан гамәлдәге законнарда билгеләнгән җир участокларын үзләштерү срокларын саклауны;

- җир участокларына хокукларны тапшыру тәртибен үтәүне;

- җирләрне тиешенчә кайтаруны;

- муниципаль милектәге җир участоклары һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участоклары өчен аренда түләвен һәм җир салымын түләүне;

- межа һәм геодезия билгеләренең булуын һәм сакланышын;

3) үз компетенцияләре чикләрендә «Дәүләт контролен һәм муниципаль контрольне тормышка ашыру барышында юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, физик һәм юридик затлар тарафыннан җирдән файдалану сорауларын җайга салучы Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм башка хокукый актлар һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр үтәлүен тикшерү;

4) санитария торышын, җәяүлеләр һәм транспорт хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, йорт ишегалдына, оешмаларга, шулай ук торак, хезмәт, сәүдә, уку, балалар һ.б. биналарга керү юлларын рәтләү, шәһәр территориясендә җир эшләрен башкаруга ордерлар бирү;

5) җир эшләрен башкару һәм төзекләндерүне торгызу мониторингын гамәлгә ашыру;

6) җир, шул исәптән аварияле-торгызу эшләрен башкаруга бирелгән ордерлар буенча эшләрнең башлану һәм тәмамлану срокларын котрольдә тоту;

7) төзекләндерү өлкәсендә тәртип бозуларны профилактикалау (шәһәрне санитар чистарту, яңа төзелеш, гамәлдәге яшелләндерелгән территорияләргә реконструкция, капиталь ремонт буенча эшләр, яшелләндерелгән территорияләрне һәм башка тышкы төзекләндерү объектларын карап тоту);

8) автомобиль юлларының, яшел утыртмаларның һәм башка тышкы төзекләндерү объектларының сакланышын тәэмин итүне контрольдә тоту, территорияләрдә яшел утыртмалар булуны тикшерү, яшел утыртмаларны юкка чыгарудан килгән зыянны исәпләү;

9) Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан коммуналь инфраструктура объектларын тиешле дәрәҗәдә эксплуатацияләүне контрольдә тоту (төзекләндерү өлкәсендә норматив хокукый актларны үтәү өлешендә);

10) Яр Чаллы шәһәрендә биналар, корылмалар һәм башка хуҗалык-көнкүреш объектларын урнаштырганда, төзегәндә, яңартып төзегәндә, сафка бастырганда, эксплуатацияләгәндә, консервацияләгәндә, ликвидацияләгәндә Төзекләндерү кагыйдәләре үтәлешен контрольдә тоту;

11) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә ачыкланган тәртип бозуларны бетерү турында «Дәүләт контролен һәм муниципаль контрольне тормышка ашыру барышында юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезендә вакытын билгеләп күрсәтмәләр бирү;

12) Төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне тәэмин итү (Яр Чаллы шәһәре территориясендә җәмәгать транспорты тукталышларында һәм тукталыш павильоннарында чисталыкны һәм тәртипне, карап тотуны тәэмин итү);

13) шәһәрнең муниципаль милкендә булган урман участокларында муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру;

14) АТИ идарәсе компетенциясе өлкәсендә җирле үзидарә мәсьәләләрен хәл итү, шулай ук шәхси ихтыяҗлар максатларында, товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, муниципаль ихтыяҗлар өчен хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән контрактлар буенча муниципаль заказчы сыйфатында катнашу;

15) билгеләнгән тәртиптә белгечләрне һәм экспертларны АТИ идарәсе эшендә катнашырга җәлеп итү;

16) АТИ идарәсе компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча методик документлар эшләү;

17) җир ресурсларын пычранудан саклау, яшел утыртмаларны саклау, зыянын хисаплап, өске агынтыны оештыру буенча чаралар эшләү;

18) атмосфера һавасына чыгарылган пычраткыч матдәләрнең таралу хисабын үткәрү;

19) АТИ идарәсе компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча норматив хокукый актлар эшләүдә катнашу;

20) шәһәр парковкаларын, шул исәптән Яр Чаллы шәһәрендә җирле әһәмияткә ия гомуми кулланыштагы автомобиль юлларын төзү, төзекләндерү, хезмәт күрсәтү һәм файдалану мәсьәләләрен заманча технологияләр кулланып һәм түләүнең акчасыз системасын кулланып хәл итү;

21) карап тикшерү АТИ идарәсе компетенциясендә булмаган тәртип бозулар ачыкланганда, мәгълүматны, материалларны башка контроль органнарга юнәлтү;

22) шәһәр бюджеты проектын формалаштыруда (АТИ идарәсе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарга кагылышлы өлешендә) катнашу;

23) АТИ идарәсе компетенциясе белән бәйле бәхәсләр буенча судларда катнашуны тәэмин итү, шул исәптән Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты исеменнән;

24) гражданнарны кабул итүне, гражданнарның телдән һәм язма мөрәҗәгатьләрен вакытында һәм тулысынча карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм гариза бирүчеләргә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокта җаваплар җибәрүне тәэмин итү;

25) муниципаль контрактлар төзүдән башка сатып алынган товарлар реестрын алып бару;

26) законнар, муниципаль актлар белән каралган нигезләрдә һәм тәртиптә башка вәкаләтләрне башкару.

## 4 бүлек. АТИ идарәсе эшчәнлеген оештыру һәм аның белән җитәкчелек итү

13. АТИ идарәсен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, башка хокукый актлар нигезендә Оештыручы тарафыннан билгеләнүче һәм эштән азат ителүче башлык җитәкли.

14. АТИ идарәсе башлыгы АТИ эшчәнлеге белән бер генә кеше идарәсе принципларында җитәкчелек итә һәм үзенең эшчәнлеге нәтиҗәләре өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Нигезләмә һәм аның белән төзелгән хезмәт килешүе чикләрендә шәхси җаваплылыкка ия.

15. АТИ идарәсе башлыгы турыдан-туры Башкарма комитет Җитәкчесенә яки аның күрсәтмәсе нигезендә башка вазыйфаи затка буйсына.

16. АТИ идарәсе башлыгы АТИ эшчәнлеген оештыру һәм тәэмин итү буенча түбәндәге функцияләрне башкара:

1) АТИ идарәсе максатлары үтәлешен тәэмин итә;

2) ышаныч язуыннан башка АТИ идарәсе исеменнән эш итә, хакимият органнарында, предприятиеләрдә, оешмаларда, учреждениеләрдә аның мәнфәгатьләре буенча эш итә;

3) АТИ идарәсе исеменнән килешүләр төзи, ышаныч кәгазьләре бирә, Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхси счет ача, законнарда һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән чикләрдә АТИ милке һәм средстволары белән идарә итү хокукыннан файдалана, үз компетенциясе чикләрендә боерыклар һәм күрсәтмәләр чыгара, АТИ идарәсенең барлык хезмәткәрләре тарафыннан үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирә;

4) Башкарма комитет Җитәкчесенә АТИ идарәсе штаты саны буенча тәкъдимнәр, АТИ идарәсе эшчәнлеген матди-техник тәэмин итүгә финанс средстволарын бүлү, кадрлар сайлау, хәзерләү, квалификацияләрен күтәрү, кызыксындыру түләүләре бирү, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче вазыйфаи затларның вазыйфаи окладларына өстәмәләр билгеләү, аларга дисциплинар җәза бирү турында тәкъдимнәр кертә;

5) АТИ идарәсе эшен планлаштыра;

6) АТИ идарәсе компетенциясе мәсьәләләре буенча әзерләнгән документларга һәм материалларга имза куя;

7) Башкарма комитет Җитәкчесе, Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарлары тарафыннан үткәрелгән АТИ идарәсе компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча киңәшмәләрдә катнаша;

8) тиешле органга билгеләнгән формаларда хисапны, шул исәптән бухгалтер һәм статистик хисапны вакытында һәм тулысынча тапшыру буенча җаваплы;

9) әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән һәм гамәлдәге законнарга каршы килмәгән башка функцияләрне башкара.

17. АТИ идарәсе башлыгы җаваплы:

1) АТИ идарәсенә йөкләнгән төп бурычларны, функцияләрне, үз вазыйфаларын башкармаган яисә тиешле дәрәҗәдә башкармаган өчен;

2) конфиденциаль һәм хезмәттәге мәгълүматларны ачкан өчен;

3) башкару һәм хезмәт дисциплинасын үтәмәгән өчен;

4) АТИ идарәсенең эш нәтиҗәләре өчен.

18. АТИ идарәсе хезмәткәрләре җаваплылыгы вазыйфаи инструкцияләр һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

19. АТИ идарәсенең муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче вазыйфаи затлары вазыйфага Башкарма комитет Җитәкчесе күрсәтмәсе нигезендә АТИ идарәсе башлыгы тәкъдиме белән билгеләнәләр һәм вазыйфадан азат ителәләр. АТИ идарәсенең башка хезмәткәрләре вазыйфага АТИ идарәсе башлыгы боерыгы нигезендә билгеләнәләр һәм вазыйфадан азат ителәләр.

## 5 бүлек. АТИ идарәсе милке һәм финанслары

20. АТИ идарәсе бюджет сметасы буенча бүлеп бирелгән милекне һәм акча средстволарын әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән бурычларны үтәү өчен файдалана.

21. АТИ идарәсе милке аңа оператив идарә итү хокукында беркетелә.

22. АТИ идарәсе аңа оператив идарә итү хокукында беркетелгән милеккә законда билгеләнгән чикләрдә эшчәнлеге максатларына, әлеге милекнең

билгеләнешенә туры китереп хуҗа була, аннан файдалана, әгәр закон белән башкасы каралмаса, Милекче ризалыгы белән әлеге милек белән идарә итә.

23. АТИ идарәсе үзенең йөкләмәләре буенча үз идарәсендә булган акча средстволары өчен җаваплы. Средстволар җитәрлек дәрәҗәдә булмаганда аның йөкләмәләре буенча мөлкәт Милекчесе – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җаваплы.

24. АТИ бюджет сметасы буенча бүлеп бирелгән средстволар хисабына алынган үзенә беркетелгән милек белән идарә итәргә хокуксыз.

25. АТИ милке һәм средстволары аның балансында чагыла һәм гамәлдәге законнар нигезендә кулланыла.

26. Милекче АТИ идарәсенә үзе беркеткән яки АТИ идарәсе тарафыннан Милекченең средстволарына алынган артык, файдаланылмаган яки билгеләнеше буенча файдаланылмаган милекне кире алырга хокуклы. Милекче Идарәдән алынган милек белән үз ихтыяры буенча эш итәргә хокуклы.

27. АТИ идарәсе милке һәм акча средстволары формалашу чыганагы булып АТИ идарәсе бюджет сметасына туры китереп, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты средстволары тора.

28. АТИ идарәсе эшчәнлеген финанс яктан тәэмин итү шәһәр бюджеты средстволары хисабына бюджет сметасы нигезендә башкарыла.

29. АТИ идарәсе кредитлар (заемнар) бирергә һәм алырга, кыйммәтле кәгазьләр сатып алырга хокуксыз. АТИ идарәсенә субсидияләр, бюджет кредитлары бирелми.

## 6 бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре

30. АТИ идарәсен юридик зат буларак үзгәртеп төзү һәм ликвидацияләү Оештыручы карары нигезендә, Россия Федерациясе законнары, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

31. АТИ идарәсе үзгәртеп төзелгәндә, аның барлык документлары гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хокукны дәвам иттерүчегә тапшырыла. Документлар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.

32. АТИ идарәсе федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә суд карары буенча ликвидацияләнергә мөмкин.

33. АТИ идарәсе ликвидацияләнгән очракта, кредиторларның таләпләрен үтәгәннән соң калган акча средстволары һәм мөлкәт Милекчегә тапшырыла.

34. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр Оештыручы карары белән кертелә һәм алар законда билгеләнгән тәртиптә теркәлергә тиеш.

35. Әлеге Нигезләмә белән хәл ителмәгән сораулар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә хәл ителә.